# КАРАР

**2022 елның 6 ноябре** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлегенең Кенәбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 06 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча 2022 елның 06 ноябрендә гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Починок Кучук авыл җирлеге Кенәбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- урам юлларына вак таш җәю (проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- юлларга асфальт салу (проект-смета документлары, техник күзәтчелек һәм экспертиза үткәрү, асфальт сатып алу, ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- су башнясын карап тоту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү);
- урам утларын карап тоту (комплектлау материаллары сатып алу һәм килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү)
- территорияне төзекләндерү һәм карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);
- тракторны карап тоту (смета һәм документлар өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, комплектлау әйберләре сатып алу, тракторчы хезмәтләре);
- янгынга каршы җиһазлар һәм комплектлау җиһазларын сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);
- чишмәне төзекләндерү (проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материалны сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- спорт инвентаре сатып алу (смета һәм документлар өчен түләү);
- видеокүзәтү системасы сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- гидротехник корылмаларны (Синерь буасы) төзекләндерү һәм карап тоту, гидротехник корылмаларга янгын техникасы керү мәйданчыгын ясау (Синерь буасы) (проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлекләренә барлыгы 235 кеше кертелде, тавыш бирүләрдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 139.

Тавыш бирүләр нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 131 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 8 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены күпчелек тавыш белән карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок-Кучук авыл җирлеге Кенәбаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныырга.

2. «2023 елда Кукмара муниципаль районының Починок Кучук авыл җирлеге Кенәбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1 900 сум күләмендә үзара салым кертүне һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүне расларга карар иттек:

- кышын-җәен урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- урам юлларына вак таш җәю (проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- юлларга асфальт салу (проект-смета документлары, техник күзәтчелек һәм экспертиза үткәрү, асфальт сатып алу, ташу һәм җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- су башнясын, су белән тәэмин итү челтәрен карап тоту һәм ремонтлау, суэтем башнясын коймалау (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү);
- урам утларын карап тоту (комплектлау материаллары сатып алу һәм килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документлар өчен түләү)
- территорияне төзекләндерү һәм карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);
- тракторны карап тоту (смета һәм документлар өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, комплектлау әйберләре сатып алу, тракторчы хезмәтләре);
- янгынга каршы җиһазлар, савытлар һәм комплектлау җиһазларын сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту, генератор сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);
- Кенәбаш авылы чишмәләрен төзекләндерү һәм карап тоту (проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- спорт инвентаре сатып алу (смета һәм документлар өчен түләү);
- видеокүзәтү системасы сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документлары, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

Карар кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Починок-Кучук авыл җирлеге башлыгы Р.А. Гыйниятов